Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре
2017-2018 уку елы
10 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 120 минут.
Максималь балл – 60.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Тартык авазларны белдерә торган хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) 13 ә) 24 б) 28 в) 39

2. *Акъяр* сүзендә **ъ** хәрефе ни өчен язылуы дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) аеру билгесен белдерү өчен

ә) иҗекне калынайту өчен

б) алынма сүз икәнен белү өчен

в) һәмзә тартыгын белдерү өчен

3. *Керфек какканчы* фразеологизмының синонимы булган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) керфеген дә селкетми

ә) керфек какмау

б) керфек кагып, күз ачып йомганчы

в) керфегеннән гөл тама

4. ***Җырлаштылар*** сүзенең мәгънәле кисәкләре дөрес күрсәтлегән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) җыр-ла-ш-ты-лар

ә) җыр-лаш-ты-лар

б) җыр-ла-ш-тылар

в) җырла-ш-ты-лар

5. Калын хәрефләр белән бирелгән фигыльгә дөрес морфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Беренче ризыгыбыз булган, зур хезмәт белән ***табылган*** *икмәккә кеше игътибары, кеше мәхәббәте кирәк.* (Ә.Еники)

а) билгеле үткән заман хикәя фигыль, затланышлы, төшем юнәлешендә, тамыр сүз, барлыкта, III зат берлек санда

ә) билгесез үткән заман хикәя фигыль, затланышлы, төшем юнәлешендә, тамыр сүз, барлыкта, III зат берлек санда

б) билгеле үткән заман сыйфат фигыль, затланышлы, төшем юнәлешендә, тамыр сүз, барлыкта, III зат берлек санда

в) билгесез үткән заман сыйфат фигыль, затланышсыз, төшем юнәлешендә, тамыр сүз, барлыкта

6. *Тау башына менеп җитү* сүзтезмәсендәге бәйләүче чара дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) башына ә) *-на* б) *-еп* в) *-ү*

7. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Бүгенге кич ник матур дип,
безгә дөнья дәшә,
Дөнья матур, шундый матур,
чөнки без янәшә. (Ф.Сафин)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

б) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә

в) катнаш кушма җөмлә

8. Җөмләдәге тыныш билгеләре дөрес куелган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Йолдыз белән алар бик тиз уртак тел таптылар кич буе гел бергә булдылар уйнадылар шаярдылар җырлап-биеп тә алдылар (З.Мостафина)

а) Йолдыз белән алар бик тиз уртак тел таптылар, кич буе гел бергә булдылар – уйнадылар, шаярдылар, җырлап-биеп тә алдылар.

ә) Йолдыз белән алар бик тиз уртак тел таптылар: кич буе гел бергә булдылар, уйнадылар, шаярдылар, җырлап-биеп тә алдылар.

б) Йолдыз белән алар бик тиз уртак тел таптылар, кич буе гел бергә булдылар: уйнадылар, шаярдылар, җырлап-биеп тә алдылар.

в) Йолдыз белән алар бик тиз уртак тел таптылар, кич буе гел бергә булдылар, уйнадылар, шаярдылар, җырлап-биеп тә алдылар.

II. Теоретик бирем.

Сүзлекләр турында белгәнегезне языгыз. ***(10 балл)***

III. Гамәли һәм иҗади бирем.

Байлык кешене тудырмый, кеше байлыкны тудыра. (Мәкаль)

1. *Байлык* сүзенә фонетик анализ ясагыз. ***(3 балл)***

2. *Кеше* сүзеннән яңа сүзләр төзеп языгыз. ***(5 балл)***

3. *Кеше* сүзенең синонимнарын языгыз. ***(3 балл)***

4. *Тудырмый* сүзенә морфологик анализ ясагыз. ***(3 балл)***

5. Җөмләгә синтаксик анализ ясагыз, схемасын сызыгыз, билгеләмә бирегез. ***(10 балл)***

6. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***